РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина, 15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

РЕШЕНИЕ

КАРАР

«18» декабрь, 2023 ел

№ 27

Кукмара шәһәре Советының 2017 елның 29 сентябрендәге 21 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Кукмара шәһәре Советы карар бирде:

1. Кукмара шәһәре Советының 2017 елның 29 сентябрендәге 21 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә (Кукмара шәһәре Советының 2018 елның 4 маендагы 7 номерлы; 2018 елның 23 ноябрендәге 24 номерлы; 2019 елның 24 маендагы 10 номерлы; 2020 елның 20 маендагы 11 номерлы; 2021 елның 16 мартындагы 6 номерлы, 2022 елның 15 июнендәге 15 номерлы, 2023 елның 13 мартындагы 28 номерлы, 2023 елның 15 ноябрендәге 20 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 нче бүлекнең 11 нче пунктында икенче җөмләне төшереп калдырырга

1.2. 4 нче бүлекнең 18 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Муниципаль хезмәткәргә класслы чин бирү турында карар, әлеге бүлекнең 12 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән очраклардан тыш, барлык кирәкле документлар белән бергә Кукмара шәәре Башлыгына класслы чин бирү турындагы тәкъдимнәр кертелгәннән соң, бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Кукмара шәһәре мэры С.Д. Димитриев